ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.12,
с.Старый Каразерик, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
СОВЕТ урамы, 12 йорт,
Иске Каразирек авылы, 423965

Тел.:(85593) 4-12-27 факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 8** **2021 елның 28 нче маеннан**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетының
2021 елның 29 гыйнварындагы «2021 елга
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Иске Каразирек авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын
раслау турында»гы 3 санлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗсанлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында 196 санлы карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетының «2021 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы 2 санлы карарына 1 һәм 2 кушымтаны әлеге карарның 1 һәм 2 кушымталары нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлегенең
2021 елның 28 нче маеннан 8 санлы
карарына 1 кушымта

2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2654,45 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (калдыкларын) зиратка илтү | 754,12 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3016,41 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлегенең
2021 елның 28 нче маеннан 8 санлы
карарына 2 кушымта

2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гүәдәне кәфенләү | 608,75 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2045,71 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта илтү | 754,12 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3016,40 |
| Барлыгы | 6424,98 |